РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ГЛАВА
Татарско-Шуганского сельского
поселения Азнакаевского
муниципального района

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Азнакай
муниципаль районы Татар Шуган
авыл җирлеге Советы
БАШЛЫГЫ

ул. Советская, д. 41в , село Татарский
Шуган, Азнакаевского
муниципального района, 423327
Тел. (факс) (85592) 36-1-41
Tshug .Azn @tatar.ru

Совет урамы, 41в, Татар Шуган
авылы Азнакай муниципаль районы,
423327
Тел. (факс) (85592) 36-1-41
Tshug .Azn @tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«30» октябрь 2020 ел №3

2021 елда Татарстан Республикасы Азнакай
муниципаль районы Татар Шуганы авыл җирлеге
Татар Шуганы торак пунктында гражданнарның
үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе
буенча гражданнар җыены үткәрү турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Татар Шуганы авыл җирлеге Уставынын 15.1 статьясы нигезендә, карар итәм:

5. Татар Шуганы авылы Совет ур., 1 нче йорттан 42,44,46,48,50 нче йортка, Тукай ур., 1 нче йорттан 45 нче йортка, Яна ур., 1 нче йорттан 9 нче йортка, Ленин ур., 1 нче йорттан 31 нче йортка, Яшьлэр ур., 1 нче йорттан 12 нче йортка кадәр теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Татар Шуганы авыл җирлеге Татар Шуганы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының беренче этабын 2020 елның 10 ноябрендэ 10.00 сәгатькә билгеләргә.

6. Татар Шуганы авылы Совет ур.,43,45,47,49,51 нче йорттан 90 нчы йортка, Жәлил ур., 1 нче йорттан 10 нчы йортка, Х.Такташ ур., 1 нче йорттан 22 нче йортка, Сэйдэш ур., 1 нче йорттан 25 нче йортка, Соембикэ ур., 1 нче йорттан 3 нчы йортка кадәр теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Татар Шуганы авыл җирлеге Татар Шуганы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенынын икенче этабын 2020 елның 10 ноябрендэ 13.00 сәгатькә билгеләргә.

7. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Сез, 2021 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, түләүне бер тапкыр киметеп 2 төркем инвалидлар өчен 150 сум күләмендә Азнакай муниципаль районы Татар Шуганы авыл җирлеге Татар Шуганы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертү

һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

- Контейнер мәйданчыклары урнаштыру (киртәләр алу өчен материаллар сатып алу, коймалар ясау һәм урнаштыру, контейнер мәйданчыклары урнаштыру (нигез, киртәләр урнаштыру); Татар Шуганы авылы, 1нче, 2нче зиратлар;
- Татар Шуганы авылы Совет , Сәйдәшев урамнары буенча юлларга вак таш җәю (вак таш сатып алу, ташу, җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Татар Шуганы авылында энергия саклаучы урам яктырткычлары, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү;
-җәйге чорда Татар Шуганы авылында территорияне чабу;
-Татар Шуганы авылы зиратларында коры агачлар кисү;
- Татар Шуганы авылында су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау (материал, җиһазлар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, торбаларны алыштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Татар Шуганы авылында «Халыкара өлкәннәр көне», «Сабантуй» бәйрәм чараларын үткәрүне оештыру;
- трактор өчен роторлы печән чапкычлары сатып алу.

« РИЗА» «КАРШЫ».

4. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Татар Шуганы авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Башлык М.Ш.Хэертдинов